**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д.Ченрнышевка, ул.Клубная, д. 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422710 Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб ур., 1

Тел./факс: +7(84365)73505, e-mail: ChernVsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
08 декабрь, 2022 ел № 9

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Чернышевка ав. территориясендә су белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләүче оешма статусын билгеләү һәм аның эшчәнлеге зонасын билгеләү турында.**

«Су белән тәэмин итү һәм су чыгару турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2 пункты һәм 12 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә органы оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Чернышевка ав. территориясендә өзлексез үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итүне оештыру максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка ав., Центральная ур., 15й адресы буенча урнашкан «Коммунальные ресурсы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә, ИНН 1616030460, ОГРН 11716900365997, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Чернышевка ав территориясендә салкын су белән тәэмин итүнең үзәк системасына хезмәт күрсәтү өчен гарантияләүче оешма статусын бирергә.

2. Эшчәнлек зонасы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Чернышевка ав. чикләрендә кушымта итеп бирелгән карта-схема нигезендә билгеләнә (сүүткәргеч челтәрләр түбәндәге урамнарда уза: Дальняя, Ульянов, Сиреневая, Солнечная, Наратлык, Озерная, Хәсән, Янтарная, Дуслык, Жасминовая, Северная, Тихая, Сәйдәшев, Татарстан, Баратынский, Мәрҗәни, Казан, Ягодная, Җәлил, Прибрежная, Высокогорская, Тукай, Балкыш, Мир, Камал, Яхин, Дорожная, Листопадная, Светлая, Рябиновая, Молодежная, Полевая, Кленовая, Луговая, Овражная).

3. «Коммунальные ресурсы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гарантияләүче оешмасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә Чернышевка ав. үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләре, гамәлдәге нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә эксплуатацияләүне.

3.2. Капиталь төзелеш объектлары билгеләнгән тәртиптә гарантияләүче оешма эшчәнлеге чикләрендә салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташкан очракта, салкын су белән тәэмин итүне.

3.3. Салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар белән ышанычлы һәм өзлексез салкын су белән тәэмин итү өчен кирәкле шартнамәләрне Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләре нигезендә төзүне.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora. tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кушымта: Татарстан Республикасы Биектау районы Чернышевка авылында салкын су белән тәэмин итү челтәрләре урнашу карта-схемасы.

Чернышевка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе О.А.Маланин